Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлегенең Мичурин исемендәге поселогы
гражданнар җыены
КАРАРЫ

2023 елның 30 ноябре №3

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Мичурин авыл җирлеге Мичурин торак пунктында "2024 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Мичурин авыл җирлегенең Мичурин исемендәге поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында" 2023 елның 18 ноябрендәге гражданнар җыены карарына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлеге Мичурин торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Мичурин авыл җирлеге Мичурин торак пунктында "2024 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Мичурин авыл җирлегенең Мичурин исемендәге поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында" 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә.

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлеге составына керүче Мичурин исемендәге поселокта гражданнар җыеннарының 2018 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы су насосы сатып алу өчен, 2021 елның 20 ноябрендәге 2 номерлы Мичурин исмемендәге поселокта су насосы бинасын ремонтлауга карарлары нигезендә җыелган гражданнарның үз-үзләренә салым салуның калган акчалары түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Мичурин исемендәге поселокта авыл эчендәге Урман урамындагы юлдагы чокырларны ремонтлау;

- Мичурин исемендәге поселокта юлларны кардан чистарту;

2) торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

каптажны тотып алу.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мичурин авылы, Совет ур., 26 йорт-административ бина, Совет ур., 28 йорт - мәдәният йорты бинасы; Яңа Сережкино авылы, Үзәк ур., 9 – авыл мәдәният йорты бинасы, Үзәк урам, 15 йорт – мәктәп бинасы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә,

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
«Мичурин авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Ә.Иванова